КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 42

«Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте» Татарстан Республикасы төбәк программасын раслау турында

Россия фәненең әһәмиятен һәм йогынтысын киңәйтү, мәдәниятара диалогны ныгыту һәм дөрес тарихи белемнәр формалаштыру мөмкинлекләрен булдыру, үткәннәрне фальсификацияләүне булдырмау максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте» Татарстан Республикасы төбәк программасын (алга таба – Төбәк программасы);

«Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте» Татарстан Республикасы төбәк программасын үтәү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап формасы..

2. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә:

Төбәк программасы чараларын чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча чикләрендә үтәүне һәм Төбәк программасында каралган максатчан күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына квартал саен, хисап кварталыннан соңгы айның 15 нче числосына кадәр, әлеге карар белән расланган форма буенча «Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте» Татарстан Республикасы төбәк программасын үтәү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына квартал саен, хисап кварталыннан соңгы айның 25 нче числосына кадәр, Татарстан Республикасы

Икътисад министрлыгына  Төбәк программасын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат җибәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карары белән расланды

# «Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте» Татарстан Республикасы төбәк программасы

## I. Гомуми нигезләмәләр

«Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте» Татарстан Республикасы төбәк программасы (алга таба – Төбәк программасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 27 декабрь, 1429 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында табигый-фәнни мәгарифне үстерү» процесслы чаралар комплексы бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән.

Төбәк программасы – Үзәк Азия һәм Көнчыгыш Европа илләреннән экспертлар җәлеп итеп, Россия фәненең әһәмиятен һәм йогынтысын киңәйтүгә юнәлдерелгән масштаблы дисциплинаара фәнни проект. Төбәк программасы мәдәниятара диалогны ныгытуга һәм ышанычлы тарихи белемнәр формалаштыру һәм тарихны фальсификацияләүне булдырмау өчен мөмкинлекләр тудыруга ярдәм итә.

Төбәк программасын гамәлгә ашыру вакыты: 2026 – 2034 еллар.

Җаваплы башкаручылар: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

Төбәк программасын гамәлгә ашыру чаралары планы аңа кушымтада китерелгән.

## II. Агымдагы хәлне анализлау

Дала Евразиясе халыкларының тарихы һәм мәдәнияте Россия цивилизациясен формалаштыруга һәм Евразия континентының тарихи-мәдәни ландшафтын формалаштыруга нигез сала. Әлеге төбәк континентның бердәмлеген һәм хәзерге Үзәк Азия һәм Көнчыгыш Европаның күп кенә илләренең дәүләтчелеген булдыруны тәэмин итеп, мәдәният һәм технологияләр трансферы пространствосы булып хезмәт итте. Әлеге феноменны өйрәнү Россия фәне өчен дә, дөнья фәне өчен дә шактый фәнни кызыксыну уята. Дала Евразиясе территориясендә халыклар һәм дәүләтләр тарихының һәм мәдәниятенең объектив дисциплинаара картинасын бирергә мөмкинлек бирә торган бердәм фәнни-тикшеренү алымнарын эшләү гаять мөһим булып тора.

Дала Евразиясе - уникаль тарихи-мәдәни киңлек, ул Россия дәүләтчелеген формалаштыруда һәм төбәк халыкларының этномәдәни үсешендә төп рольне уйнады. Трансконтиненталь элемтәләр ярдәмендә әлеге төбәк Евразиянең бердәмлегенә, Үзәк

Азия һәм Көнчыгыш Европаның заманча илләренә йогынты ясаган эре дәүләт берәмлекләре һәм мәдәниятләре барлыкка килүгә ярдәм итте. Дала Евразиясенең тарихи-мәдәни мирасы, матди һәм язма мәдәниятне дә кертеп, дөньякүләм мәдәни байлыкның бер өлеше буларак комплекслы өйрәнү һәм саклауны таләп итә. Әлеге тарихи һәм цивилизацияле феноменны өйрәнү илебез фәне өчен дә, дөнья фәне өчен дә җитди кызыксыну уята.

Хәзерге вакытта төбәкнең бөтен киңлегендә һәм киң хронологик диапазонда Дала Евразиясенең күчмә культураларын үстерү моделен булдыруны комплекслы дисциплинаара тикшеренүләр гамәлгә ашыручы фәнни программалар юк.

Булган тикшеренүләргә карамастан, комплекслы дисциплинар якын килү таләп итә торган бер төркем хәл ителмәгән мәсьәләләр саклана, алар арасында иң мөһиме:

Дала Евразиясе халыкларының үсеш динамикасын өйрәнүгә методик һәм методологик алымнарны билгеләү, төрки халыкларның дәүләтчелеген аякка бастыру, Көнчыгыш һәм Көнбатыш цивилизацияләренең бу процессларга йогынтысын, борынгы һәм Урта гасырларда сәясәткә һәм икътисадка мәдәни трансфертларның йогынтысын билгеләү;

дәүләтчелек формаларының, далада хакимлек итүче династияләренең, дала дәүләтләренең социаль структураларының тарихын карау, әлеге традицияләрне вакыт һәм киңлекләрдә күчерү һәм трансформацияләү, төрки-татар дәүләтчелегенең Россия дәүләтен торгызуга йогынтысы;

йомышлы татарларны рус гаскәренә һәм дворян сословиесенә кертү, аларның Россиянең дала чикләрен саклауда тоткан рольләре. «Татарлар» этнонимының тарихи язмышын тикшерү аеруча кызыксыну уята, ул бүген дә фәнни һәм иҗтимагый тирәлектә актив фикер алышулар предметы булып кала бирә.

күчмә һәм утрак мәдәниятләрнең үзара хезмәттәшлеге, төрле цивилизацияләр, дөнья диннәре йогынтысы һәм, димәк, дала зонасы халыкларының рухи мәдәнияте трансформациясе; Идел буе һәм Урал буе халыкларының сословие структурасын тикшерү;

урбанизация процессларын, шәһәр мәдәниятен формалаштыру динамикасын, аның тел һәм язу үсешенә йогынтысын өйрәнү, шул исәптән: тел элемтәләрен һәм үзара бәйләнешләрне анализлау, яңа аралашу телләрен, язуларны формалаштыру, әдәби традицияләрне булдыру;

халыкара трансъевразия сәүдә юлларын (Идел-Балтыйк, Бөек Ефәк, Чәй юллары) өйрәнү, аларның дәүләтчелек, шәһәр структурасы һәм Дала Евразиясе халыклары мәдәнияте формалашуындагы роле һәм әһәмияте, хуҗалык процесслары динамикасына йогынтысы;

проблематиканың комплекслы чыганагын үстерү: Дала Евразиясе тарихы буенча яңа чыганаклар бастырып чыгару, дөнья, шул исәптән төрки, монгол, кытай һәм, һичшиксез, Россия тарихын өйрәнү, татар халкы һәм аның бабалары тарихы буенча чыганаклар җыелмасын борынгы заманнардан алып яңа вакытка кадәр булдыру.

Әлеге өлкәдәге хәзерге проблемаларга шулай ук түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

археологик һәйкәлләр, архитектура объектлары һәм эпиграфик чыганакларның җитәрлек өйрәнелмәве һәм югалу куркынычы;

татар халкының тарихы һәм мәдәнияте һәйкәлләренең системалаштырылган җыентыгы булмау, бу аларны исәпкә алу, өйрәнү һәм популярлаштыруны кыенлаштыра;

Алтын Урда һәм Казан ханлыгының (XIII – XVI гасырлар) эпиграфик һәйкәлләрен фәнни реставрацияләү, каталоглаштыру һәм фәнни әйләнешкә кертү ихтыяҗы;

Волга-Урал төбәге халыкларының башка дәүләтләр белән элемтәләр тарихын чагылдырган киң документлар катламын өйрәнү һәм бастыру;

элек фәнни әйләнешкә кертелмәгән материалларны ачыклау, цифрлаштыру һәм бастыру өчен махсус архив проектларын гамәлгә ашыру кирәклеге;

үткәннең мифлаштырылган һәм бозылган интерпретацияләрен таратуга китерә торган дөрес фәнни публикацияләр булмау. Фальсификацияләргә каршы тору механизмнарын эшләү таләп ителә, шул исәптән эксперт дискуссияләрен һәм фәнни-популяр проектларны да кертеп;

халыкара хезмәттәшлекнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы. Евразия тарихи-мәдәни мирасын комплексы өйрәнү өчен уртак экспедицияләрне, конференцияләрне, басмаларны да кертеп, халыкара хезмәттәшлекне көчәйтү таләп ителә.

Евразия илләреннән, дөньяның аерым илләреннән экспертлар җәлеп итеп, төбәк программасын гамәлгә ашыру Россия фәненең әһәмиятен һәм йогынтысын киңәйтә, мәдәниятара диалогны ныгытуга һәм ышанычлы тарихи белемнәр формалаштыру өчен мөмкинлекләр тудыруга ярдәм итә. Һәрьяклап һәм масштаблы фәнни хезмәттәшлек Дала Евразиясенең гомуми тарихи-мәдәни мирасын «хосусыйлаштыру», аның нигезендә милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрдә киеренкелек тудыручы этноцентрик концепцияләр төзү омтылышларын чикләүгә ярдәм итәчәк.

Фәнни җәмгыятьнең бурычы, шул исәптән Төбәк программасын гамәлгә ашыру кысаларында, – тарихи үткәннең фальсификациясенә каршы тору, традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрен һәм тарихи хәтерне саклап калуга һәм ныгытуга ярдәм итү.

Шулай итеп, Дала Евразиясе - уникаль тарихи-мәдәни киңлек, ул Россия дәүләтчелеген формалаштыруда һәм төбәк халыкларының этномәдәни үсешендә төп рольне уйнады. Трансконтиненталь элемтәләр ярдәмендә әлеге төбәк Евразиянең бердәмлегенә, Үзәк Азия һәм Көнчыгыш Европаның заманча илләренә йогынты ясаган эре дәүләт берәмлекләре һәм мәдәниятләре барлыкка килүгә ярдәм итте. Дала Евразиясенең тарихи-мәдәни мирасы, матди һәм язма мәдәниятне дә кертеп, дөньякүләм мәдәни байлыкның бер өлеше буларак комплексы өйрәнү һәм саклауны таләп итә.

## III. Төбәк программасының максаты һәм бурычлары

Программаның максаты – Дала Евразиясе халыкларының тарихи-мәдәни мирасын һәрьяклап өйрәнү, саклау һәм популярлаштыру. Төбәк программасы төбәкнең бөтен киңлегендә һәм глобаль контекстта Дала Евразиясе мәдәниятләре үсешенеңербөтен фәнни моделен формалаштыруга, киң хронологик диапазон дәвамында төбәк халыклары һәм дәүләтләре тарихында һәм мәдәниятендә әлеге

мирасның дәвамчанлыгын ачыклауга юнәлтелгән. Дала Евразиясе мирасын өйрәнү һәм саклау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыру фәндә булган җитешсезлекләрне тулыландыруга, тарихны фальсификацияләүгә һәм халыкара фәнни хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлдерелгән актуаль бурыч булып тора. Күрсәтелгән юнәлешләрдә системалы чаралар эшләү тарихи хәтерне саклауны һәм төбәкнең үткәне турында объектив белемнәр формалаштыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге миссия уртак тарихи киңлек белән берләшкән халыклар арасында үзара аңлашуны ныгытырга һәм тупланган белемнәрне дөньяви фәнни һәм мәдәни кырга интеграцияләүне тәэмин итәргә тиеш. Программа дисциплинаара характер йөртә һәм илебез һәм чит ил экспертлары белән хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла, бу аның халыкара әһәмиятен ассызыклый.

Куйган максатка ирешү өчен Төбәк программасы эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча төркемләнгән берничә төп бурычны хәл итүне күздә тота:

1. Тарихи-мәдәни (этнологикны да кертеп) тикшеренүләр.

Дала Евразиясе халыклары үсешенең тулы картинасын булдыруга юнәлтелгән комплекслы тарихи, культурологик һәм этнографик тикшеренүләр үткәрү. Әлеге юнәлеш кысаларында дала төбәгендә күпмилләтле җәмгыятьләр һәм дәүләтчелек формалаштыру процесслары, күчмә һәм утрак халыкларның мәдәни мирасының дәвамлылыгы һәм үзара йогынтысы гасырлар дәвамында, шулай ук дала цивилизацияләренең Россия һәм дөнья тарихын үстерүгә керткән өлеше өйрәнелә. Әлеге тикшеренүләрнең нәтиҗәләре Дала Евразиясе мәдәниятләре үсеше закончалыкларын аңлата торган яңа фәнни модельнең нигезенә ятачак.

2. Архив һәм археологик эшләр.

Яңа чыганакларны табу һәм фәнни әйләнешкә кертү максатында масштаблы архив тикшеренүләрен һәм кыр археологик экспедицияләрен гамәлгә ашыру. Бурычлар Дала Евразиясе халыклары тарихы белән бәйле үзебезнең һәм чит ил архивларында тарихи документларны ачыклау, системалаштыру һәм өйрәнү, шулай ук дала төбәгендәге археологик һәйкәлләрне казу һәм фәнни тикшеренүне үз эченә ала. Ачыкланган артефактлары Евразия далалары халыкларының тормыш, көнкүреш, сәүдә һәм мәдәни элемтәләре турында белемнәрнең матди базасын тулыландырырга мөмкинлек бирәчәк дөньякүләм-тарихи әһәмияттәге объектларга аерым игътибар бирелә. Археология эшләре барышында алынган мәгълүматлар алдагы тикшеренүләр һәм тарихи реконструкцияләр өчен эмпирик нигез булачак.

3. Фәнни һәм популяр әдәбият бастыру.

Үткәрелгән тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен һәм аудиториянең төрле категорияләре өчен билгеләнгән басмалар һәм электрон басмалар әзерләү һәм аларны чыгару. Дала Евразиясе халыклары тарихының һәм мәдәниятенең төрле аспектларын яктыртучы фундаменталь фәнни хезмәтләр: монографияләр, фәнни мәкаләләр җыентыгы, энциклопедик сүзлекләр һәм белешмәлекләр чыгару планлаштырыла. Иң мөһим нәтиҗәләрнең берсе, мәсәлән, Дала Евразиясе археологиясе һәм дала цивилизацияләре турында монографияләр сериясе буенча энциклопедик сүзлек чыгару булачак. Параллель рәвештә популяр әдәбият - фәнни-популяр китаплар, альбомнар, буклетлар бастыру күздә тотыла, алар киң даирә укучыларга дала халыкларының бай мирасы һәм галимнәрнең яңа ачышлары турында сөйли. Мондый

басмалар җәмгыятьнең Дала Евразиясе тарихы белән кызыксынуын арттыруга һәм белемнәрне таратуга ярдәм итәчәк.

4. Мәдәниятләр диалогын үстерү.

Дала Евразиясе белән тарихи бәйле халыклар арасында мәдәниятара диалогка ярдәм итү һәм багланышларны ныгыту. Әлеге бурыч төбәкнең төрле этнослар, тел һәм дини төркемнәре вәкилләрен җәлеп итүче мәдәни-агарту чараларын һәм дискуссия мәйданчыкларын оештыру аша тормышка ашырыла. Гомуми тарихи-мәдәни мирасны объектив һәм хөрмәт белән кабул итүне формалаштыруга юнәлтелгән түгәрәк өстәлләр, күргәзмәләр, уку семинарлары һәм башка инициативалар уздыру күздә тотыла. Тарихны бозуга каршы көрәшкә аерым игътибар бирелә: белем һәм уртак проектлар белән ачык алмашу тарихи фактларны фальсификацияләүгә юл куймаска ярдәм итәчәк һәм мәдәни диалогта катнашучылар арасындагы ышанычны ныгытачак.

5. Форумнар һәм конференцияләр оештыру.

Төбәк программасы тематикасы кысаларында төбәкара һәм халыкара дәрәҗәдәге даими фәнни форумнар, конференцияләр һәм семинарлар уздыру. Галимнәрнең үзара хезмәттәшлеге, тикшеренүләр нәтиҗәләре белән алмашу һәм уртак эшчәнлекне координацияләү өчен мәйданчыклар булдыру планлаштырыла. Төбәк программасын гамәлгә ашыру барышында Евразия далаларының Халыкара археология конгрессы, Халыкара Алтын Урда форумы һәм Евразия дала поясы тарихының һәм мәдәниятенең төп проблемаларына багышланган зур масштаблы чаралар оештыру күздә тотыла. Әлеге форумнар һәм конференцияләр Төбәк программасы мәнфәгатьләре белән берләшкән фәнни бергәлек формалаштырырга, арадаш эш нәтиҗәләре турында фикер алышырга һәм тикшеренүләрнең яңа юнәлешләрен билгеләргә мөмкинлек бирәчәк. Моннан тыш, алар Төбәк программасын популярлаштыруга һәм халыкара академик җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итүгә хезмәт итә.

6. Цифрлаштыру һәм мәгълүматларны бастыру.

Региональ программасын гамәлгә ашыру барышында алынган мәгълүматны саклау һәм тарату өчен заманча цифрлы ресурслар булдыру. Әлеге юнәлеш кысаларында Дала Евразиясе халыклары мирасына караган Россия һәм чит ил музейларында, китапханәләрендә һәм архивларында саклана торган этнографик, тарихи һәм археологик материалларны цифрлаштыру планлаштырыла. Тикшеренүчеләрнең һәм кызыксынган кулланучыларның беренче чыганакларга, фотоархивларга, артефактларга һәм Төбәк программасының фәнни-аналитик материалларына ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итүче мәгълүматларның, каталогларның һәм коллекцияләрнең электрон базалары формалаштырылачак. Төбәк программасының рәсми веб-сайтын булдыру һәм даими яңарту каралган, анда тикшеренүләр нәтиҗәләре, уздырыла торган чаралар турында яңалыклар, виртуаль күргәзмәләр һәм башка интерактив материаллар бастырылачак. Цифрлы технологияләрне болай куллану Төбәк программасы аудиториясен киңәйтергә һәм киләчәк буыннар өчен уникаль мәгълүматларның сакланышын тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

7. Төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлек.

Дала Евразиясен өйрәнү белән кызыксынган төрле төбәкләрнең һәм илләрнең фәнни-тикшеренү үзәкләре арасында хезмәттәшлекне үстерү. Программа Идел буе,

Урал, Себер, Үзәк Азия, Көнчыгыш Европа һәм башка төбәкләр республикалары академик институтларының һәм университетларының көчләрен берләштерә. Уртак экспедицияләр һәм тикшеренүләр, галимнәр һәм аспирантлар алмашу, ике яклы һәм күп яклы проектлар үткәрүне күздә тоткан партнерлык элемтәләре урнаштырыла. Чит ил коллегалары катнашында хезмәттәшлек турында килешүләр төзү, координация советлары һәм эш төркемнәре төзү планлаштырыла. Мондый төбәкара һәм халыкара эш форматы төрле тәҗрибәне һәм белемнәрне синтезларга, бер төбәктән читтә дә уникаль чыганакларга керүне тәэмин итәргә һәм тикшеренүләрнең гомуми дәрәҗәсен арттырырга тиеш.

8. Программаның күп тармаклы якын килүе һәм халыкара масштабы.

Төбәк программасы халыкара форматта гамәлгә ашырыла һәм комплексны дисциплинар алымга ия. Анда төрле фәнни өлкәләрдән: тарих, археология, этнография, антропология, филология һәм культурология экспертлары актив катнаша.

Мондый алым өйрәнелә торган мәсьәләләрне бөтен тулылыгы белән карарга мөмкинлек бирә, Дала Евразиясендә барган катлаулы процессларны тирәнтен аңлау өчен методларны һәм төрле фәнни дисциплиналарга ирешүне берләштерә. Бер үк вакытта Төбәк программасы үзенең составы буенча халыкара программа булып тора: тикшеренүләрдә һәм чараларда Россиянең күп кенә төбәкләреннән, шулай ук чит илләрдән галимнәр катнаша. Аерым алганда, Үзәк Азия, Көнчыгыш Европа, Кавказ һәм Евразиянең башка өлешләренең тикшеренү берләшмәләре белән хезмәттәшлек җайга салынган. Күпсанлы галимнәр һәм оешмалар көчләрен берләштерүче Төбәк программасының масштаблы характеры уздырыла торган эшләрнең югары фәнни дәрәҗәсен һәм нәтиҗәләрне дөнья фәнни контекстына интеграцияләүне тәэмин итә.

## IV. Төбәк программасының максатчан күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2031 ел | 2032 ел | 2033 ел | 2034 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1. | Әзерләнгән һәм бастырылган басма продукция саны, берәмлек | 12 | 13 | 18 | 24 | 21 | 20 | 26 | 19 | 32 |
| 2. | Әзерләнгән видеороликлар саны, берәмлек | 5 | 12 | 12 | 10 | 12 | 10 | 11 | 10 | 11 |
| 3. | Үткәрелгән һөнәри чаралар саны, берәмлек | 7 | 16 | 11 | 10 | 11 | 13 | 10 | 10 | 11 |
| 4. | Үткәрелгән фәнни экспедицияләр саны, берәмлек | 11 | 12 | 9 | 10 | 9 | 9 | 9 | 7 | 5 |
| 5. | Тикшерелгән татар тарихы һәм мәдәнияте һәйкәлләре саны, берәмлек | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Оештырылган күргәзмәләр саны, берәмлек | 0 | 4 | 0 | 0 | 1 | 3 | 0 | 1 | 3 |

## V. Төбәк программасын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр

Төбәк программасы гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә:

төбәкнең бөтен киңлегендә һәм киң хронологик диапазонда Дала Евразиясе культураларын үстерү моделен булдыру;

Дала Евразиясе халыкларының мәдәниятләрен өйрәнүдә бердәм методология һәм методиканы билгеләү;

Дала Евразиясе илләренең бердәм фәнни киңлеген булдыру;

Дала Евразиясе халыкларының һәм илләренең тарихи-мәдәни мирасының бердәм цифрлы киңлеген булдыру;

фәнне, шул исәптән тарихи, археологик, лингвистик, этнологик, культурологик белемнәрне популярлаштыру;

традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрен һәм тарихи хәтерне саклап калу һәм ныгыту;

дөрес фәнни белемнәр формалаштыру һәм үткәнне фальсификацияләү омтылышларына каршы тору;

академик, фәнни-популяр, фәнни-белешмә басмалар, видеоматериаллар булдыру;

Евразия илләре, шулай ук дөньяның аерым илләре галимнәре катнашында фәнни форумнар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр үткәрү;

халыкара мәгълүмат системаларын булдыру, тутыру һәм аларга ярдәм итү.